ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БИЕШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

КАРАРЫ

2024 ел, 3 июнь № 167

Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычны түләттерү ышанычсыз булуны тануга өстәмә нигезләр билгеләү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясындагы 3 пункты, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының «Биеш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Биеш авыл җирлеге Советы карар итте:

1.2024 елның 1 гыйнварына аерым салым түләүчеләргә исәпләнелә торган, түбәндәге нигезләр буенча түләү һәм (яисә) түләттерү мөмкин булмаган җирле салымнар суммалары өлешендәге бурыч түләнүгә ышанычсыз дип танылa:

1) варислар мираска хокуктан баш тарткан, варислар булмаган яисә мирас ачылган көннән бер ел дәвамында мирас кабул итеп алынмаган очракта, үлгән яисә вафат булган физик затларның бурычы булу;

2) 2024 елның 1 гыйнварына кадәр юкка чыгарылган җирле салымнар буенча оешмаларга яисә шәхси эшмәкәрләргә исәпләнә торган бурыч булу;

3) Россия Федерациясе Салым кодексының 48 статьясында билгеләнгән сроклар тәмамланганнан соң физик затларның 500 сумнан артмаган суммада бурычы булу.

2. Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычны түләтүгә ышанычсыз дип тануның өстәмә нигезләре булуын раслаучы документлар:

1) әлеге карарның 1 пунктының 1 пунктчасында күрсәтелгән нигез булганда:

а)бурыч суммасы турында физик затның яшәү урыны буенча салым органы белешмәсе;

б)вафат булуга бәйле рәвештә, физик затны салым органнарында исәптән алу хакындагы белешмәләр;

в)мираска хокук турында таныклык бирү хакындагы белешмәләрнең булмавы турында салым органы белешмәсе;

2)әлеге карарның 1 пунктының 2 пунктчасында күрсәтелгән нигез булганда:

а) бурыч суммасы хакында оешманы, шәхси эшкуарны, шәхси эшкуар статусын югалткан физик затны исәпкә алу урыны буенча салым органы белешмәсе;

б)салымны юкка чыгаруга нигез булган норматив хокукый акт турындагы белешмәләр (исеме, датасы, номеры);

3) әлеге карарның 1 пунктының 3 пунктчасында күрсәтелгән нигез булганда - 500 сумнан артмаган суммада бурыч булу хакында салым органының белешмәсе.

3. Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Биеш авыл җирлеге Советының «Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычны түләтүгә ышанычсыз дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында» 2023 елның 14 августындагы 12 номеры карарын үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карарны интернетта - "Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы" (pravo.tatarstan.ru) ресурсында бастырып чыгарырга. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының рәсми сайтында (apastovo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

5. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

6.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Биеш авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Апас муниципаль районы
Биеш авыл җирлеге башлыгы Р.А. Валиев